Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы
Келәнче авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2019 елның 11 феврале № 96

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлеге Советының 2017 елның 8 сентябрендәге “Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында”гы Нигезләмә хакында” 48 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә, гамәлдәге законнар нормаларына тәңгәлләштерү максатларында Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлеге Советының 2017 елның 8 нче сентябрендәге 48 нче номерлы карары белән расланган “Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында”гы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 11 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктчасын «сәяси партия» сүзеннән соң «билгеләнгән тәртиптә теркәлгән профсоюз» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендлар аша халыкка белдерергә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Келәнче авылы, Г.Тукай ур., 35нче йорт;
- ТР, Кама Тамагы районы, Бәки авылы, Фрунзе ур. шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуын үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Келәнче авыл җирлеге Башлыгы,
Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Келәнче авыл җирлеге Советы рәисе Д.А.Кадыров.